**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# О внесении изменений в Указ Президента Республики Татарстан «О перечне должностных лиц, входящих в состав Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан»

В соответствии со статьями 94 и 100 Конституции Республики Татарстан, статьями 9 и 15 Закона Республики Татарстан от 6 апреля 2005 года № 64-ЗРТ «Об исполнительных органах государственной власти Республики Татарстан» **постановляю**:

1. Внести в Указ Президента Республики Татарстан от 18 сентября 2020 года № УП-590 «О перечне должностных лиц, входящих в состав Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан» следующие изменения:

а) в пункте 2 слова «Премьер-министр Республики Татарстан имеет девять заместителей, в том числе одного первого заместителя Премьер-министра Республики Татарстан, трех заместителей Премьер-министра Республики Татарстан» заменить словами «Премьер-министр Республики Татарстан имеет десять заместителей, в том числе одного первого заместителя Премьер-министра Республики Татарстан, четырех заместителей Премьер-министра Республики Татарстан»;

б) в перечне должностных лиц, входящих в состав Кабинета Министров Республики Татарстан – Правительства Республики Татарстан:

дополнить новым абзацем шестым следующего содержания:

«Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан»;

абзацы шестой – тридцать четвертый считать абзацами седьмым – тридцать пятым соответственно.

2. Кабинету Министров Республики Татарстан:

обеспечить в установленном порядке финансирование расходов, связанных с реализацией настоящего Указа;

привести свои акты в соответствие с настоящим Указом, а также принять иные решения, обеспечивающие его реализацию.

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Президент**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
14 июля 2022 года
№ УП-478

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Конституциясенең 94 һәм 100 статьялары, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында» 2005 елның 6 апрелендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 15 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлеге турында» 2020 елның 18 сентябрендәге ПУ-590 номерлы Указына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 пунктта «Татарстан Республикасы Премьер-министрының тугыз урынбасары, шул исәптән бер Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, өч Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Премьер-министрының ун урынбасары, шул исәптән бер Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары, дүрт Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте составына керүче вазыйфаи затлар исемлегендә:

түбәндәге эчтәлекле яңа алтынчы абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары»;

алтынчы – утыз дүртенче абзацларны тиешенчә җиденче – утыз бишенче абзацлар дип санарга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;

үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2022 ел, 14 июль
№ ПУ-478